# КАРАР

**№19** **25 февраль 2021 ел**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында Түбән Көек авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел, № 102 карарына үзгәрешләр кертү турында»

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Уставы нигезендә, Түбән Көекавыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ.:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел, № 102 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү:

**1.1. Нигезләмәнең 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 абзац өстәргә:**
- инициативалы проектларны тәкъдим итү , әзерләү ,сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә »;
1.2. 3. 20 пунктны түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:
« Әгәр гражданин җитди сәбәпләр ( сәламәтлек ,инвалидлык һ. б.) буенча гражданнар җыенында катнаша алмаса, гражданинның фамилиясе ,исеме һәм атасының исеме , аның яшәү урыны , аның гражданнар җыенында катнаша алмавы сәбәбе , шулай ук аның гражданнар җыенына чыгарыла торган үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсенә турыдан-туры мөнәсәбәте аның гаризасы нигезендә гражданнар җыенында исәпкә алына».
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында , Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (pravo.tatarstan.ru ) веб –адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл җирлеге
башлыгы




Д.М. Галиәхмәтов